# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№ 2 27.11.2023 ел

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Иске Матвеевка авыл җирлегенең Калморза торак пунктында
2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иске Матвеевка авыл җирлегенең Калморза торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Калмурзино Иске Матвей авыл җирлеге Калмурзино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда үзара салым акчаларын 500 сум итеп кертергә, моңа түбәндәгеләр керми: көндезге формада белем алучы студентлар, I һәм 2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнар, аларның гаилә әгъзалары.

2.Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлтергә:

- Калморза торак пунктында Яңа урамдагы юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, китертү, салу, килешү буенча эшләр өчен түләү).

Халык җыенында рәислек итүче: _______________ М.Н. Галимҗанов
(имза) (имзаның аңлатмасы)

Иске Матвеевка авыл җирлеге башлыгы,
Советы рәисе _______________ М.Н.Галимҗанов
(имза) (имзаның аңлатмасы)